**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан и признании утратившей силу статьи 2 Закона Республики Татарстан «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
10 июня 2015 года

**Статья 1**

Внести в Земельный кодекс Республики Татарстан (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 января 2005 года № 4-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 8 (II часть); 1999, № 8 (I часть); 2005, № 1 (I часть), № 12 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 1 (I часть), № 4; 2008, № 5 (I часть); 2009, № 7 – 8 (III часть); 2010, № 11; 2011, № 11 (I часть); 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть) следующие изменения:

1) в статье 25:
а) в пункте 3:
в подпункте 2 слово «захламления» заменить словом «загрязнения»;
подпункт 3 изложить в следующей редакции:
«3) защите сельскохозяйственных угодий от зарастания деревьями и кустарниками, сорными растениями, а также защите растений и продукции растительного происхождения от вредных организмов (растений или животных, болезнетворных организмов, способных при определенных условиях нанести вред деревьям, кустарникам и иным растениям);»;
в подпункте 4 слова «, и захламления» заменить словом «загрязнения,»;
в подпункте 6 слова «в хозяйственный оборот» заменить словами «земель в оборот»;
б) абзац первый пункта 6 изложить в следующей редакции:
«6. Для оценки состояния почвы в целях охраны здоровья человека и окружающей среды Правительством Российской Федерации устанавливаются нормативы предельно допустимых концентраций вредных веществ, вредных микроорганизмов и других загрязняющих почву биологических веществ.»;

2) дополнить статьей $33^2$ следующего содержания:

«Статья $33^2$. **Предоставление земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, некоммерческим организациям для освоения территории в целях строительства и эксплуатации наемных домов социального использования**

Земельные участки, находящиеся в государственной или муниципальной собственности, предоставляются на срок до пяти лет для освоения территории в целях строительства и эксплуатации наемных домов социального использования некоммерческим организациям, созданным Республикой Татарстан или муниципальными образованиями для освоения территории в целях строительства и эксплуатации наемных домов социального использования, в аренду без проведения торгов в случае, если:

1) некоммерческая организация является участником государственной или муниципальной программы по освоению территории в целях строительства и эксплуатации наемных домов социального использования;

2) аукционы на право заключения договора об освоении территории в целях строительства и эксплуатации наемного дома социального использования в отношении конкретного земельного участка не менее двух раз подряд признаны несостоявшимися и с лицом, подавшим единственную заявку на участие в аукционе, с заявителем, признанным единственным участником аукциона, или с единственным принявшим участие в аукционе его участником не заключен договор об освоении территории в целях строительства и эксплуатации наемного дома социального использования.»;

3) дополнить статьей $35^1$ следующего содержания:

«Статья $35^1$. **Приобретение в собственность земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности и предоставленных сельскохозяйственным организациям и крестьянским (фермерским) хозяйствам для осуществления их деятельности на праве постоянного (бессрочного) пользования или праве пожизненного наследуемого владения**

1. Земельные участки из земель сельскохозяйственного назначения, предоставленные сельскохозяйственным организациям или крестьянским (фермерским) хозяйствам для осуществления их деятельности на праве постоянного (бессрочного) пользования или праве пожизненного наследуемого владения, приобретаются указанными лицами в собственность по цене, равной 10 процентам кадастровой стоимости сельскохозяйственных угодий, если на таких участках отсутствуют здания или сооружения.

2. Земельные участки, расположенные в границах населенных пунктов и предназначенные для ведения сельскохозяйственного производства, которые предоставлены сельскохозяйственным организациям или крестьянским (фермерским) хозяйствам для осуществления их деятельности на праве постоянного (бессрочного) пользования или праве пожизненного наследуемого

владения, приобретаются указанными лицами в собственность по цене, равной 10 процентам их кадастровой стоимости, если на таких участках отсутствуют здания или сооружения.

3. Арендатор земельного участка, который предоставлен из земель сельскохозяйственного назначения или земель населенного пункта и предназначен для ведения сельскохозяйственного производства и на котором отсутствуют здания или сооружения, вправе приобрести такой земельный участок в собственность по цене, равной 10 процентам его кадастровой стоимости, в случае, если право аренды этого арендатора возникло в результате переоформления права постоянного (бессрочного) пользования или права пожизненного наследуемого владения таким земельным участком на право аренды.».

**Статья 2**

Статью 2 Закона Республики Татарстан от 28 апреля 2007 года № 18-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 4; 2014, № 5) признать утратившей силу.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Временно исполняющий обязанности
Президента Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
1 июля 2015 года
№ 45-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм "Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяда:

а) 3 пунктта:

2 пунктчада "чүпләнүдән" сүзен "пычранудан" сүзенә алмаштырырга;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән яклау, шулай ук үсемлекләрне һәм үсемлектән ясалган продукцияне зарарлы организмнардан (билгеле бер шартларда агачларга, куакларга һәм башка үсемлекләргә зарар салырга сәләтле үсемлекләрдән яисә хайваннардан, авыру китерен чыгаручы организмнардан) яклау;";

4 пунктчада "чүпләнүеннән" сүзен "пычрануыннан" сүзенә алмаштырырга;

6 пунктчада "үз вакытында хуҗалык әйләнешенә кертү" сүзләрен "җирләрне үз вакытында әйләнешкә кертү" сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Кеше сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында туфракның торышын бәяләү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан зарарлы матдәләрнең, зарарлы микроорганизмнарның һәм җирне пычрата торган

башка биологик матдәләрнең рөхсәт ителә торган иң чик концентрацияләре нормативлары билгеләнә.”;

2) түбәндәге эчтәлекле $33^2$ статья өстәргә:

“$33^2$ статья. **Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга бирү**

Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен Татарстан Республикасы яисә муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен түбәндәге очракларда торглар үткәрелмичә биш елга кадәр вакытка арендага бирелә:

1) коммерциягә карамаган оешма социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү буенча дәүләт яисә муниципаль программаларда катнашса;

2) социаль файдаланудагы наем йорты төзү һәм аннан файдалану максатларында территорияне үзләштерү турында билгеле бер җир кишәрлегенә карата шартнамә төзү хокукына аукционнар кимендә ике мәртәбә булмаган дип танылса һәм аукционда катнашуга гариза биргән бердәнбер зат белән, аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган гариза бирүче белән яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы белән социаль файдаланудагы наем йортын төзү һәм аннан файдалану максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзелмәгән булса.”;

3) түбәндәге эчтәлекле $35^1$ статья өстәргә:

“$35^1$ статья. **Авыл хуҗалыгы оешмаларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен милеккә алу**

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән авыл хуҗалыгы оешмаларына яисә крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән җир кишәрлекләре, әгәр мондый кишәрлекләрдә биналар яисә корылмалар булмаса, күрсәтелгән затлар тарафыннан милеккә авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләренең кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән алына.

2. Торак пунктлар чикләрендә урнашкан һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы оешмаларына яисә крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану

хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән җир кишәрлекләре, әгәр мондый кишәрлекләрдә биналар яисә корылмалар булмаса, күрсәтелгән затлар тарафыннан милеккә аларның кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән алына.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән яисә торак пункт җирләреннән бирелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе алып бару өчен билгеләнгән, биналары һәм корылмалары булмаган җир кишәрлеген арендага алучы, шушы арендаторның аренда хокукы мондый җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукын аренда хокукына яңадан рәсмиләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән очракта, мондый җир кишәрлеген кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән милеккә алырга хокуклы.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 28 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяны (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4; 2014, № 5) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 45-ТРЗ